ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

19 08 2024 г. № 862

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрү тәртибе турында» 2018 нче елның 23 нче октябрендәге 925 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставының 75 статьясы нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрү тәртибе турында» 2018 елның 23 октябрендәге 925 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 3 нче кушымтасында:

2 нче бүлектәге алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль милектәге яисә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә һәм муниципаль учреждениеләргә бирелгән хокукларга карата - җир кишәрлегенең хокук иясе»;

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.И. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов